
Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы
# Мәктәп пульсы



№2
Октябрь 2018 г.

## С днём учителя!

*Дорогие учителя!*

Благодарим Вас от души
За доброту и за терпение!
Желаем радостей больших,
В работе Вашей вдохновения,

Старательных учеников,
Тетрадок самых аккуратных,
И в классе каждый день цветов,
И больше праздников приятных!



*С уважением, редколлегия газеты!*

## Укытучы – бәхетле кеше

***Ай, нинди көн, нинди көн бу***
***Кыздыра кояш көзне.***
***Шул кояштай якты сыман***
***Укытучылар көне!***

Дөньяда бик күп яхшы һөнәрләр бар. Минемчә, алар бөтенесе дә кирәкле. Тик укытучы һөнәре иң әйбәт һөнәр ул. Укытучы һәрвакыт балаларга ярдәм итә. Ул һәр кешене язарга, укырга өйрәтә. Укытучы булу җиңел түгел. Моның өчен күп белергә, балаларны яратырга һәм хөрмәт итә белергә кирәк.

Минем уйлавымча, укытучы - ул үз тәҗрибәсен балаларга бирә торган кеше. Әмма, укытучы, шулай ук, һәрвакыт укучыларга үрнәк бирергә тиеш. Юкка гына алаарны икенче ана дип атамыйлар бит.

Иң беренче мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып, зур тормышка озатып соңгы кыңгырау чыңлаган көнгә кадәр бала белән һәрчак янәшәдә аның Укытучысы атлый.

Ул аны белем дөньясына алып керә, яхшыны яманнан аерырга, хезмәт һәм иҗат шатлыгын тоярга, аңардан шәхес тәрбияләргә бөтен көчен куя. Укытучы барлык һөнәрләргә юл ачучы. Күпкырлы, ээләнүчән, тәрбияче, могҗиза кылучы.

Чын укытучы – бәхетле кеше, чөнки аның кулында бөтен кешелек бәхете.

**Алмаз АСАДУЛЛИН,**
9Б сыйныфы

## Интересно знать!

- В среднем в день человек делает более 18 000 шагов.
- На протяжении жизни человек съедает около 27 тонн пищи, что равняется весу семи слонов.
- На шахматной доске разнообразных комбинаций больше, чем в нашей Вселенной атомов.
- Чтобы заснуть, нормальному человеку требуется в среднем 7 минут.
- В среднем мухи живут не более 2-х 3-х недель.
- Емкость мозга человека превышает 4 терабайта.

## В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Автоматтан ату - кызлар эше түгел! | 2 |
| Күңелле очрашу | 3 |
| Без - “Бумеранг” форумында | 4 |
| Буыннар чылбыры | 4 |
| "Татарча диктант" акциясе | 5 |
| Минем туган ягым | 5 |

# Автоматтан ату - кызлар эше түгел!

**“Ватанга тугъры калырга, яшь армиячеләр туганлыгына тап төшермәскә, намуслы һәм гадел булырга, ярдәмгә мохтаҗларны якларга, укуда һәм спортта уңышларга ирешергә!” – бу Юнармия хәрәкәте активисты Гөлфинәнең тормыш шигаре. Кем икән бу дип уйлап куйдыңмы? Хәзер барысын да үзең белерсең!**

**- Гөлфинә, Юнармия хәрәкәтенә син ничек килеп эләктең?**

- Мин кечкенәдән бирле туган илләрен данлаган кешеләр белән горурлана идем. Аларны мин изге кешеләргә тиңлим. Шул чакта ук мин тормышымны хәрби хезмәт белән бәйлисем килде. Тиздән хыялым максатка әверелде. 2016нчы елның көзендә мин яшь армиячеләр рәтенә кердем. Бик тиздән юнармиячеләрнең иң алдынгылары исеменә үсеп җиттем дисәм дә, ялгыш булмас. Яшь армиячеләр иҗтимагый хәрәкә-тендәге эшчәнлегем өчен орден белән бүләкләндем.

**- Әлеге орденны алыр өчен нишләргә кирәк соң?**

- Минемчә, эшчән, акыллы, ярдәмчел, бар яктан да уңган булуын күрсәткән һәр яшь армияче бу бүләккә лаек була ала.



Әлбәттә, укудагы уңышлар, физик яктан нык булу да зур йогынты ясый. Актив булырга кирәк, шул чакта гына сине күреп алачаклар. Тырыш-лыгым аркасында ТНВ каналының иң кызыклы тапшыруларының берсе – “Башваткыч”та катнашу бәхете елмайды. Хәзерге җиңүләрем – минем бердәнбер горурлыгым! Бер-ике ел элек көрәзәчеләр киләчәкне юраган булсалар, мин аларның әйт-кәннәренә ышанмаган да булыр идем әле!

**- Орден алуга якыннарың ничек карады?**

- Өйгә кайтып, зур уңышым турында сөйләгәч, алар сүзсез калды. Әмма горурлыктан балкыган йөзләреннән барысы да аңлашыла иде инде! Әлеге күренеш минем күңелемне тагын да күтәреп җибәрде, чөнки гаиләм ярдәм иткән эшкә минем йөрәк җылым да кереп бара. Яраткан сыйныфташларым, укытучыларым да чын күңелдән котлады. Сыйныфым үзе бер зур гаилә бит, шуңа күрә һәрберебезнең кечкенә булса да җиңүе безнең барыбызга да кагыла.

**- Хәрби әзерлек буенча дәрес-ләрдә син нәрсәләргә өйрәндең?**

- Бу сорауга мин сәгатьләр буе җавап кайтара алам. Иң мөһимнәрен генә әйтеп китим: туган иленне яратырга, өлкәннәргә, нәни дусларыбызга карата дустанә мөнәсәбәт белән карарга, физик күнегүләрнең иң авырларын да дөрес итеп үтәргә өйрәндем. Хәзер командабыз белән беренче медицина ярдәме күрсәтә, автоматны сүтеп җыя, бердәм команда булып стройда йөри беләбез. Күптәннән бирле автоматтан атарга өйрәнәсе килә иде. Юнармия хәрәкәте миңа шушы хыялымны чынга ашырырга ярдәм итте. Башта куллар да калтырады, мишеньга эләгә алмыйча җафа чигеп, җиргә дә аткалаган чаклар булды. Ә хәзер исә... кулга автомат кына тоттырсыннар! Баш өстендәге алмага да эләктерә алам! Боларның барысына да без хәрби әзерлек буенча дәресләр үткәрүче укытучыбыз Илдус Аскаров ярдәме белән ирештек.

**- “Автоматтан ату - кызлар эше түгел!” – дип уйлаганың да булмады мени?**



- Булды, бик күп булды андый уйлар! Сугышырга өйрәнгән чакларда да алар баштан чыкмады. Төрке-мебездә бердәнбер кыз булганга, үз-үзеңә ышану, үзең белән горурлану да арта. Бу миңа ярты юлда туктап калмаска, алга таба атларга этәргеч биреп тора.

**- Әллә армиягә дә барыр идеңме?**

Әйе! Кечкенә чакта солдат булам, армиягә барам дип йөри идем. Тик үсә төшкәч бу фикергә кире борылып та карамадым! Бер дә пләш каласы килми шул! – дип шаярта үзе.

**- Чын яшь армияче, синеңчә, нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

- Юнармияче туган илен ярат-ырга, чын ватанпәрвәр булырга тиеш. Туган илне саклау мәсьәлә-сендә кешеләргә карата мөнәсәбәт аеруча мөһим, шуңа күрә кешелеклелек сыйфатлары да үз ролен уйныйдыр, миңа калса. Туган җиреңне саклау - күпкырлы билгеләмә, аңа турыдан-туры илне саклау гына түгел, ә анда яшәүче халыкны да саклау керә.

*(Дәвамы 3нче биттә)*

# Автоматтан ату - кызлар эше түгел!

**- Юнармия хәрәкәтенән тыш тагын нинди иҗимагый файдалы эшләр белән шөгыльләнәсең?**

- Мин “21нче гасыр волонтерлары” оешмасының вәкиле дә әле. Без бергә балалар бакчаларына, картлар йортына, реабилитация үзәкләренә барып, концертлар куябыз, төрле кызыклы акцияләрдә актив катнашып, кешеләргә ярдәм итү мәсьәләләрен чишәбез.




**- Буш вакытың каламы соң синең, Гөлфинә? Нинди хобби-ларың бар?**

- Буш вакытым күп түгел, юк дисәм дә була. Мәш килеп фән олимпиа-даларына, БДИга әзер-ләнәм! Ләкин җай көне футбол уйнарга яратам. Әйе, әйе, футбол! Яратып җан аткан командам да бар – Реал Мадрид. Кечкенә чакта шаяра-шаяра туп тибеп уйнаган уеным хәзер яшьлек шөгылемә әйлән-де. Өемдә китаплар коллекциясе бар, бәйләргә, чигергә дә яратам. Тарих белән кызыксынам, китаплар укыйм, шигырьләр язам, җырларга-биергә дә кире тормыйм. Кешегә бар һөнәр дә эз -әләп салынган дип саныйм. Аны бары тик куәтләндерегә генә кирәк. Шуңа күрә үземне төрле яктан сынарга тырышам.

**- Барысына да ничек өлгереп бететергә соң? Уңыш серен белән уртаклаш әле.**

Көн тәртибеңне тиешлечә оештыра белсәң – уңыш синең кулда дигән сүз. Шул бәхетне тоткансың икән – беркүк ычкындыра күрмә! Инстаграм, ВКонтактеда утырып, вакытыңны әрәм итмәскә тырыш. Интернет челтәрендә эленеп калырсың тагын! Көндәлек ясап, шунда һәрбер эшлисе эшеңне теркәп барырга тәкъдим итәм. Әмма эш белән дә артык мавыгырга да ярамый. Укыганда физик күнегүләр ясаштырганнарга кирәк. Ялыңны файдалы итеп уздырырга кирәген дә исеңнән чыгара күрмә.

**- Гөлфинә, ә син нәрсә турында хыялланасың?**

- Имтиханнарымны уңышлы тапшырып, киләчәктә Эчке эшләр министрлыгында эшлисем килә. Аның өчен мин бик күп тырышам, көч түгәм. Шуңа күрә дә әлеге хыялымның һичшиксез чынга ашуына ышанасы килә.

***Илебезнең киләчәге Гөлфинә кебек кую яшьләр кулында! Чыннан да, аның үз антына тугъры калачагына, барлык авырлыкларны җиңәргә үзендә көч табачагына сез дә инангансыздыр!***

**Рүзәл ШӘРИПОВ**,
9Б сыйныфы

# Күңелле очрашу

***Табигатьнең шушы матур вакытында бөтен дөньяда Өлкәннәр көне үткәрелә. Бу вакыйгага Арчаның 2 нче номер-лы мәктәбе коллективы да бик җитди әзерләнә.***

Алдан ук чакыру кәгазьләре тапшырыла. Ә инде 1 нче октябрь көнне мәктәптә чын бәйрәм. Мәктәпкә килгән һәр пенсионер укытучыны кояштай балкып каршы алалар. Мәктәпкә хәзер барып торасы килә: матур, чиста, җылы, ишегалдында искиткеч чәчәк-ләр үсә. Ә инде актлар залына кергәч, үзеңне зур концертлар залында дип хис итәсең.

Бәйрәмне Саляхова Альбина Абдулловна ачып җибәрде, үзенең матур теләкләрен әйтте. Концертны 7 А класс уку-чылары укытучының бихисап эшен чагылдырган программа күрсәттеләр. Балалар шундый оста чыгыш ясыйлар, матур итеп җырлыйлар, бииләр, шигырь сөйлиләр. Беренче класс укучысы нәни Фархуллина Сафина үзенең җыры белән, барабызны шаккаттырды. Балаларның ос-талыгына сокланып, рәхәт-ләнеп концерт карадык. Житәкчеләре – музыка укытучысы Мухаметгалиева Алина Фирдинатовна.

Бәйрәм мул итеп әзерләгән табын артында дәвам итте. Яшьлек елларыбызны, мәк-тәптә булган кызык вакыйгаларны искә төшереп, көлеп, җырлап утырдык, рәхәтләнеп сөйләштек. Безгә, өлкәннәргә, шундый гүзәл бәйрәм оештырган өчен, барлык мәктәп коллективына зур рәхмәт.

**Нурфия ШӘЙХИЕВА**
*Лаеклы ялдагы укытучы*

# Буыннар чылбыры


***Укытучы... Бу сүзне әйтүгә чәчләренә чал кергән олы кешенең дә, беренче сыйныф укучысының да күзалдына хәреф таныткан беренче укытучысы килеп баса. Соңгы вакытта укытучы һөнәренә бераз караш үзгәрде дибез. Чынлапта бу шулай микән соң? Шушы сорау белән мин үзем эшләгән коллектив укытучылары турында уйлан-дым.***

Безнең мәктәптә югары белемле, зур тәҗрибәгә ия булган укытучылар белем бирә. Кайсы гына мөгаллимнең үз укучысын белемле, әдәпле, тәрбияле итеп күрәсе килми икән!

*(Дәвамы 4нче биттә)*

# Без - “Бумеранг” форумында

Каләм тибрәтүче балаларга киләчәктә журналист булып китү өчен зур мөмкинлекләр бар. Шундый мөмкинлекләрнең берсе Бөтенрәсәй балалар һәм яшьүсмерләр өчен үткәрелгән Краснодар өлкәсенең “Орленок” лагеренда “Бумеранг” форумында катнашу.




Шушы форумга катнашу бәхетенә мәктәбебездән ике укучы иреште: мин - Зөләйха Зәбирова һәм Салават Замалиев. Поезддан төшүгә безне вожатыйлар каршы алды. Нинди конкурста җиңүебезгә карап, безне төрле отрядларга бүлделәр. Лагерьда төрле эш юнәлешләре алып барылды. Һәркем үзенә ошаган эш төрен дәвам итте.. Отрядыбызда балалар Рәсәйнең төрле почмакларыннан килгән иде. Беркем дә үзенә яңа дуслар таба алмыйча кайтмады. Смена беткәндә бер-беребез белән туганлашып беттек.

Һәр көн мавыктыргыч кичәләр, экскурсияләр, җылы диңгездә йөзү белән бай иде.

Кара диңгездә су коену аеруча рәхәт иде. Комлы яр буенда яланаяк йөреп һич туймадык.

“Бумеранг” тормышы “Орленок “ лагере белән тыгыз бәйләнештә тора. Кич белән бөтен отряд җыйналып бер-беребезгә




тыныч төннәр теләмичә йокларга ятмый идек. Бу “Орленок” традицияләренең берсе.

Беркөнне лагерь ачылу тантасыннан кайтканда, мин кояш батканын күрдем.

Шәфакъ кып-кызыл, диңгез ялтырый. Шундый җылы тымызык һава. Әкрен генә караңгы төшә.

Урамда үсеп утырган алоэ, гөлҗимешләр күз алдымда һаманда тора.

**Зөләйха ЗӘБИРОВА,**
10Б сыйныфы

# Буыннар чылбыры

...Көнне һәм төнне белмичә хезмәт куялар алар.

Ә иң кызыгы шунда,шул укыткан укытучыларның укучылары туган мәктәпләренә эшкә кайталар. Алар: Сәләхова Альбина Абдулловна, Гыйниятуллина Гөлнара Илдус кызы, Әхмәдиева Райлә Фархулла кызы, Галиуллина Клара Рәхим кызы, Малафеевская Алла Вячеслав кызы, Гарипова Гөлнар Алфред кызы, Миннибаева Ләйсән Рафаил кызы, Прыткова Найлә Фәрит кызы, Аскаров Илдус Равилулы, Сәйфуллина Алсу Равил кызы....

Быелгы уку елында алар рәтен Закирова Альбина Рамил кызы, Шакиров Булат Фаил улы тулыландырды .

Закирова Альбина Рамил кызы рус теле һәм әдәбияты укытучысы. Кызның күңеленә рус теле һәм әдәбиятына мәхәббәтне остазы Сәләхова Альбина Абдул кызы уята. Укытучысының рус язучылары әсәрләре белән таныштыруын ул кызыксынып тыңлый, аның белән бергә шул геройларның хис – кичерешләрен кичерә. Укучының күңелендә: “Мин дәукытучы булам” дигән уй туа. Аңарда укытучы һөнәренә мәхәббәт хисе уяна. Шул юлны сайлый ул. Хыялы аны Казан Федераль Университетына алып килә. Бүгенге көндә ул туган мәктәбендә рус теле укытучысы булып эшли.

Ә Шакиров Булат исә туган мәктәбенә Спорт һәм туризм Академиясен тәмамлап кайта.

Эшли башлавына ай гына булса да, ул инде укучылары арасында ихтирам уятты. Энергиясе кайнап торган, заманча технологияләрне үзләштергән егет мәктәбебезгә зур уңышлар алып килерәле.

Директорыбыз Гыйниатуллина Гөлназ Гали кызы яшь кадрларны җылы каршы ала, үзенең киңәшләрен бирә.

Димәк, укытучы һөнәрен бүгенге көн яшьләре дәвам итәләр икән. Ак юл сезгә, яшь педагоглар!

**Эльмира ЗӘБИРОВА**

# Минем туган ягым

Минем туган ягым – җырларда җырланган, шигырьләрдә язылган данлыклы Арча төбәге. Шәһәребезнең табигате дә искиткеч матур. Ул яшел тугайлы болыннарга, балыклы елгаларга, урманнарга, җиләкле аланнарга бай. Туган ягымның һавасы гына ни тора! Миндә туган ягымны сөю, ярату хисе бәләкәй чактан бирле бар.





Арча ягы – Тукай ягы. Арча төбәге бик күп язучылар һәм шагыйрьләр биргән як.Тукайның шигырьләрендә анық изге теләкләре, бәхеткә булган өметләре урын алган. Арча шулай ук музейларга бай. Анда “Әлифба”, “Тукай” музейлары эшли.

Арчаның нәкъ уртасында “Дан” мемориаль комплексы урнашкан. Ул Бөек Ватан сугышында катнашучыларга багышлап төзелгән. Арчабызның үзәгендә язучылар аллеясы да бар. Анда Габдулла Тукай, Гомәр Баширов, Гариф Ахунов һәм Мөхәммәт Мәһдиев бюстлары урын алган. Көннән – көн зурая хәм матурлана Арча. Төзелешләр киң колач белән бара. Ул төзеклеге, пөхтәлеге һәм матурлыгы белән сокландыра.

Арчамны мин бик яратам!

**Карина ЖАМАЛИЕВА,**
5Б сыйныфы

# "Татарча диктант" акциясе



27 октябрь көнне безнең мәктәптә Бөтендөнья "Татарча диктант" акциясе үтте. “Татарча диктант” – татар телендә хатасыз язарга өйрәтү, әдәби татар телен кулланучылар даирәсен арттыру, орфографик һәм грамматик хаталарны тикшерү мәсьәләләренә игътибарны арттыручы белем бирү акциясе.

Татарча диктант
Яз.

Бу чарада теләге булган һәр кеше катнаша ала иде. Әлеге мәйданчыкта барлыгы 45 укытучы катнашты. Алар арасында төрле фән укытучылары бар иде. Г.Исхакыйның "Көз" әсәреннән өзекне мәгариф идарәсе методисты Э.Г.Мостафина укыды.


**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Дизайнер - верстальщик*** Рузаль Шарипов
***Фотокорреспондент*** Диана Галимова
***Корректор*** Данил Степанов
***Редколлегия*** Алия Хабирова
Гузель Насибуллина
***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15
***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2

1972
Арск
школа №2